КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 3 апрель г.Казань № 263

Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен түләүне гражданнарның аерым категорияләренә компенсацияләүгә Татарстан Республикасы чыгымнарын финанслашу өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен мөмкин булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен түләүне гражданнарның аерым категорияләренә компенсацияләүгә Татарстан Республикасы чыгымнарын финанслашу өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2019 елның 8 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 3 апрель, 263 нче
карары белән расланды

Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен түләүне гражданнарның аерым категорияләренә компенсацияләүгә Татарстан Республикасы чыгымнарын финанслашу өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану
кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.3 статьясы нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертем өчен түләүне финанслашу өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр (алга таба – субсидия) рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану тәртибен билгели.

2. Федераль бюджеттан субсидия Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсендә (алга таба – Ккзначылык) ачылган шәхси счетка керә.

3. Субсидияләрне тоту Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылыктан бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм субсидияне финанслауның иң чик күләмнәре турында мәгълүмат алганнан соң биш эш көне эчендә Казначылыкка аның гаризалары буенча Министрлыкка финанслауның иң чик күләмнәрен җиткерүгә чыгым расписаниясен тапшыра.

5. Министрлык Казначылыктан субсидияне финанслануның чик күләмнәрен җиткерүгә чыгымнар расписаниясен алганнан соң биш эш көне эчендә алга таба гражданнарның кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына күчерү яки почта элемтәсе аша яшәү урыны буенча илтеп җиткерүне гамәлгә ашыру өчен Казначылыкка «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба – Үзәк) субсидияләрне финанслауның иң чик күләмнәрен җиткерү өчен чыгым расписаниясен тәкъдим итә.

6. Үзәк квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 13 числосыннан да соңга калмыйча, Министрлыкка финанслашу максатларында субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында, шулай ук субсидия куллану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре зурлыгына ирешү хакында хисап тапшыра.

7. Министрлык квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына аларны финанслашу максатларында субсидия бирелә торган, шулай ук субсидия кулланының нәтиҗәлелеге күрсәткечләре зурлыгына ирешү турында Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

8. Әлеге Кагыйдәләрнең 6 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән хисаплар Россия Федерациясе Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан субсидия бирү турында килешүнең типик формасын раслау хакында» 2018 елның 14 декабрендәге 269н номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан субсидия бирү турында килешүнең типик формасына 10 нчы һәм 11 нче кушымталар нигезендә форма буенча бирелә.

9. Субсидияләрнең агымдагы финанс елында файдаланылмаган өлеше Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидиянең файдаланылмый калган өлеше федераль бюджет кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә федераль бюджет кеременә алынырга тиеш.

10. Акчаларны максатсыз файдалану Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.